**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

_____________ № ______

Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының Актаныш звеносы идарәсе органнары һәм көчләре өчен Актаныш муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәл режимын кертү турында

2023 елның май, июнь айларында Актаныш муниципаль районы территориясендә, авыл хуҗалыгы предприятиеләре җирләрендә аномаль югары температура шартларында, озакка сузылган явым-төшем дефициты нәтиҗәсендә, бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культуралары өчен туфракта продуктив дым запасының тиз югалуы күзәтелә. Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә зур матди зыян салынды.

"Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында" 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә авыл хуҗалыгы культураларының үлүенә китергән «коры җир», «туфрак корылыгы» һәм «атмосфера корылыгы» куркыныч табигый агрометеорологик күренешләр комплексы нәтиҗәсендә барлыкка килгән азык-төлек куркынычсызлыгы куркынычын булдырмау максатларында, "Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында" 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 3 июлендәге 222 номерлы боерыгы белән Актаныш муниципаль районы өчен гадәттән тыш хәл режимы кертелде һәм региональ дәрәҗәдә җавап бирү билгеләнде, шуңа бәйле рәвештә,

**боерам:**

1. «Татмедиа» «Актаныш-информ» АҖ Актаныш филиалына, гадәттән тыш хәл режимын кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкны мәгълүматлаштыруны тәэмин итәргә.

2. Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм катлаулы табигый факторларның тискәре нәтиҗәләрен бетерү гамәлләрен үтәү өчен җәлеп ителә торган көчләрне тәэмин итү буенча комиссиянең эшче төркеме составын кушымта нигезендә расларга.

3. Эшче төркем утырышларын атнага кимендә бер тапкыр үткәрергә, кирәк булса - көн саен.

4. Актаныш муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгына ике эш көне дәвамында эшче төркеменә корылыкка бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча чаралар планын тәкъдим итәргә.

5. Актаныш янгын-коткару гарнизоны башлыгына, район предприятиеләре, оешмалары җитәкчеләренә 2020 елның 18 ноябрендәге пр-228 номерына ярашлы

рәвештә, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының район звеносы көчләренең әзерлеген һәм оператив реакциясен тәэмин итәргә.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Расланган
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
күрсәтмәсе белән

_______________2023 ел №______

**Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм катлаулы табигый факторларның тискәре нәтиҗәләрен бетерү чараларын үтәү өчен җәлеп ителә торган көчләрне тәэмин итү буенча комиссиянең эш төркеме составы (килешү буенча)**

| | |
|---|---|
| Ильясов Р.А. | - эш төркеме җитәкчесе, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Мортазин И.М. | - эш төркеме җитәкчесе урынбасары, Актаныш янгын сүндерү-коткару гарнизоны башлыгы. |

**Эш төркеме әгъзалары: (килешү буенча)**

| | |
|---|---|
| Сәлимгәрәев Н.Ә. | - Актаныш муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы; |
| Гыймадиев А.Р. | - «Татмедиа» «Актаныш-информ» АҖ Актаныш филиалы директоры; |
| | - авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре” |
| Әхмәтгалиев Ә. Х. | - “Минзәлә урманчылыгы” ДКУ участок урманчысы. |